Гыйнвар № 6

# Энҗе бөртекләре

Татар телендә белем бирүче 18 гимназиянең рәсми газетасы

## Бу санда


«Без яшь чакта...» **1**

Гимназия хәбәрләре **2**

Гимназия хәбәрләре **3**

Күңелле тәнәфес **4**


## *«Без яшь чакта– кар койма биеклеге була иде, көрәп бетерә алмый азаплана идек...»*

“Ай, урамда бигрәк салкын”,- дигән сүзләрне бик еш ишетәм әле мин соңгы арада. Без, кешеләргә, шулай инде, ярап булмый. Җылы булса– нишләп кыш көне шулай җылы соң, буран чыкса– каян чыкты бу буран дип, гел баш ватабыз, зарланабыз. Ә бит, кыш көне салкын булырга тиеш! Безнең әби– бабайларыбызның сүзләренә колак салсак, түбәндәге сүзләрне еш ишетергә туры килә: “Без яшь чакта– кар койма биеклеге була иде, көрәп бетерә алмый азаплана идек, ә урамдагы салкын турында әйтеп тә торасы юк”.

Кыш– кыш инде ул. Салкын булсын. Табиблар әйтүенә караганда– салкын һава торышы торганда төрле микробларның, вирусларның да үрчү тизлеге кими. Тик менә урамга чыкканда, җылы итеп киенергә, табигый чималдан булган тукымаларга өстенлек бирергә кирәк (синтетик тукыма җылыны тотмый). Бигрәк тә хәзер, грипп сезоны көчәеп киткәндә, иммунитетыбызга игътибар бирү дә комачау итмәс. Ә иммунитетны күтәрү өчен без сезгә: күбрәк С витамины кергән җиләк– җимешләр ашарга, саф һавада йөрергә, имбирьлы чәй эчәргә киңәш итәбез.

***********************************

Зарыгып, дулкынланып көтеп алган Яңа ел да үтеп китте. Укучыларыбыз кышкы каникулдан чыгып, тырышып укыр өчен бүген, 9 нчы гыйнвар көнендә, кабаттан гимназия бусагасыннан атлап керделәр. Алда аларны иң озын- III чирек

# Гимназия хәбәрләре

көтә. Укучыларыбыз! Яңа чиректә без Сезгә зур тырышлык, түземлелек бары әйбәт билгеләр генә теләп калабыз.

20 яшькә кадәр юниорлар арсында **җиңел атлетика буенча шәхси беренчелектә** катнашып, 800 һәм 1500м аралыкларны



йөгереп узып, ике дистанция буенча да **III урын алган** 10 нчы сыйныф укучысы **Хөсәенов Фазылны** чын күңелдән **котлыйбыз**! Фазылның– алга таба да спорт белән "дус" яшәвен дәвам итеп, югарыдан–югары үрләр яулавын теләп калабыз. *Укытучысы:* ***Максимова Елена Ивановна***.

*************************************

**22 нче декабрьдә** урта һәм югары сыйныф укучылары өчен **"Яңа ел дискотекасы"** оештырылды. Бирәдә укучылар төрледән– төрле конкурсларда катнашып, Кыш бабай һәм Кар кызыннан истәлекле бүләкләр дә алдылар.

Шулай ук, **23 нче декабрь** көнне, 1 нче сыйныф укучылары өчен **«Чыршы әйләнәсендә»** дип аталган җыр– биюле, уенлы чара узды. Укучылар бик тырышып Кыш бабай һәм Кар кызы өчен концерт номерлары, теләкләр, шигырьләр, театраль өзекләр әзерләгәннәр иде. Балалар чыршы әйләнәсендә Яңа ел турында җырлар җырлап, уеннар уйнап күңелле



ял иттеләр, көн буена җитәрлек күтәренке кәеф алдылар.

*************************************

## Яшел түгәрәк акциясе

16 нчы декабрь көнне «Яшел түгәрәк» акциясе уңаеннан гимназиябез укучылары тарафыннан **2058** килограмм 400 грамм тотылган кәгазь җыеп тапшырылды.

Иң күп макулатура җыючылар итеп башлангыч сыйныфлар арасында **1А** ( 1урын), **3А** (2 урын), **4Б** (3 урын), ә югары сыйныфлардан **7А** (1 урын), **8Б** (2 урын), **6А** (3 урын) укучылары табылдылар.

# Гимназия хәбәрләре



22 нче гыйнвар көнне гимназиябез директоры Садыков Равил Хасаншовичның олы бәйрәме– 60 яшьлек юбилее– туган көне.

Равил Хасаншович! Сезгә карап, беркем дә әле 60 яшь бирә алмый, Сез бит һәрвакыт тулы энергияле, эш җанлы, ярдәмчел, сабыр кешесез. Коллективта зур ихтирамга лаексыз, чөнки, гимназияне «гаилә» итүгә бик зур өлешегезне кертеп, зур тырышлык куясыз.

Чыннан да, биредә, коллективка яңа гына килеп кергән укытучыларны гел якты йөз белән каршы алалар, ярдәм итәләр.

Сезнең бик әйбәт директор икәнне гимназиядә эшләүчеләр генә түгел, ә бөтен Татарстан, Рәсәй белә: 2005 елда гимназия «Мәгариф» милли проекты юнәлешендә абсолют лидер булса, 2008 елда инде ул Рәсәйнең Мактау китабына кертелде.

Ә бит Сезнең казанышлар моның белән генә бетми. Сез шул ук вакытта бик әйбәт мөгаллим дә («Ел укытучысы» шәһәр конкурсында «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» номинациясендә җиңүче), чөнки Сездә белем алган укучыларның берсе дә тормышта югалып калмыйча, югары дәрәҗәләргә ирешеп, чын кеше булып яшиләр. Гимназиядә чын татар рухын, татар мөхитен үстерүгә керткән өлешегез өчен аерым зур рәхмәтебезне җиткерәбез Сезгә.

Барлык гимназия коллективы исеменнән без, Сезне, туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә, иң мөһиме, саулык–сәламәтлек, тынычлык, сабырлык телибез. Бөтен гомeрегезне, көчегезне гимназия данын үстерүгә багышлаган көчле зат буларак, эчкерсезлегегез, ихласлылыгыз белән бөтен кешеләрнең хөрмәтен яуладыгыз. Һәрвакытта да ярдәмчел, гадел директорыбыз, укытучыбыз булып калыгыз. Алга таба да бер зур гаилә булып эшләргә насыйп булсын.

Тормышыгызның иң ямьле чагы,
60 яшь– ул аз әле!
Алда әле- күпме шатлык
Күпме бәхет, наз әле.

Гомерне бит еллар билгеләми,
Яшәү дәрте булсын күңелдә.
Сәламәтлек, бәхет, куанычлар
Юлдаш булсын Сезгә, гомергә.

Олы хөрмәт һәм ихтирам белән: 18 нче гимназия коллективы.

# Күңелле тәнәфес

Казан урамы буйлап троллейбус бара. Йөртүче тукталышларны игълан итеп тора:
- Киләсе тукталыш Сыртланова.

Үтеп китәләр.

- Сыртланова тукталышы. Киләсе тукталыш Гарифьянов.

Тагын үтеп китәләр.

_ Гарифьянов. Киләсе тукталыш бертуган Касимовлар...

Шунда йөртүче янына бер бабай килә дә:
- Улым, минем фамилия Хабибуллин. Миңа кайчан төшәргә?

**********************************

- Айнур, минем компьютерым эшләми.
- Анда бер зур төймә бар, аңа басып карадыңмы?
- Әйе, барыбер эшләми.
- Розеткага тыкканмы?
- Белмим, хәзер шырпы кабызам да карыйм.
- Ә шырпы нигә?
- Бездә утны сүндерделәр

**********************************

Әтисе улына:

- Улым, син үсеп җиттең инде, кем булырга уйлыйсың?

- Әти, мин Кыш бабай булырмын ахры!

- Нишләп? !

- Нишләп дип, чөнки ул Яңа елга кадәр бер атна һәм Яңа елдан соң бер атна гына эшли.

************************************

Урыс теле дәресендә:

- Рустем, телефон звОнит или звонИт???

-Белмим, Марья Ивановна, у меня шалтырата!

************************************

Бер профессор үзенең коллегаларына сөйли:
-Төш күрәм, имеш мин студентларга лекция укыйм. Уянып китсәм, чынлап та лекция укыйм икән!

************************************

Кадерле укучылар! Сезгә газетабызның бу саны ошады дип өметләнеп калабыз! Киләсе айга материалларыгызны газета редакторына тапшыра аласыз.

**Газета өстендә эшләделәр:**

**Редакторлар:**
Айгөл Хәлимовна Закирова

**Корреспондентлар:**
Айгөл Хәлимовна Закирова

**Фото:**
Айгөл Хәлимовна Закирова

**Тираж:** 30 экз.

**Бастыру вакыты:** 2017 елның гыйнваре.